МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.07.2017 г. Казань № 604 од

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә яллаучы вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибе турында

2004 елның 27 июлендә кабул ителгән № 79-ФЗ “Россия Федерациясендә дәүләт гражданнар хезмәте турында”гы Федераль законның 1 нче маддәсе 3 нче пункты нигезендә БОЕРАМ:

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә яллаучы вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибе турындагы закон.

1. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә яллаучы вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибен расларга (алга таба - Тәртип).

2. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Министр А.М. Сибагатуллин

Татарстан Республикасы
мәдәният министрының
25.07.2017 № 604-од
боерыгы белән
расланган

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә яллаучы вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибе

1. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә яллаучы вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибе (алга таба - Тәртип) 2004 елның 27 июлендә кабул ителгән № 79-ФЗ "Россия Федерациясендә дәүләт гражданнар хезмәте турында"гы Федераль законның 1 нче маддәсе 3 нче пункты нигезендә эшләнгән.
   Бу Тәртип Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә яллаучы вәкил тарафыннан бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре) түләүсез нигездә иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, дача кулланучылар кооперативы, күчемсез милекчеләр ширкәте (алга таба – коммерцияле булмаган оешма) белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү процедурасын регламентлый.
   Бу Тәртип Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында (алга таба - Министрлык) яллаучының вәкиле Татарстан Республикасы мәдәният министры булган (алга таба - Министр) гражданлык хезмәткәрләренә кагыла.
2. Бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар белән идарәдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү турында гариза (алга таба - Гариза) гражданлык хезмәткәре тарафыннан язма формада бу Тәртипкә 1 нче Кушымта буенча төзелә.

3. Гражданлык хезмәткәре Гаризаны коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча җаваплы затка (алга таба – Җаваплы зат) тапшыра.

4. Җаваплы зат Гаризаны алынган көнне бу Тәртипкә 2 нче Кушымта нигезендә Журналда терки.

5. Җаваплы зат Гаризаны карый һәм аның нәтиҗәләре буенча йомгак ясый.

Җаваплы зат Гаризаны башлангыч карау вакытында Гариза биргән гражданлык хезмәткәреннән коммерцияле булмаган оешма идарәсендә планлаштырылган катнашу буенча функцияләрен билгеләүче язма аңлатма һәм документлар соратып ала ала.

Нәтиҗәдә гражданлык хезмәткәренә түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарәдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында тәкъдим булырга тиеш.

6. Гариза теркәлгәннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча җаваплы зат Гаризаны Нәтиҗәле кушымта һәм башка материаллар белән бергә (булган очракта) министрга (аның вазифаларын башкаручыга) гражданлык хезмәткәренә түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарәдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен тапшыра.

Министр (аның вазифаларын башкаручы) Гариза алынганнан соң ике эш көне дәвамында карар кабул итә.

7. Җаваплы зат министр (аның вазифаларын башкаручы зат) карар кабул иткәннән соң ике эш көне дәвамында гражданлык хезмәткәренә Гаризаны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм аңа кул куйдырып кадрлар бүлеге мөһере сугылган министр резолюциясе булган Гариза күчермәсен тапшыра. Министр резолюциясе белән Гаризаның оригиналы гражданлык хезмәткәренең шәхси эшенә өстәлә.

______________________________

Татарстан Республикасы дәүләт
гражданлык хезмәткәренә яллаучы
вәкил тарафыннан Татарстан
Республикасы Мәдәният
министрлыгында бер генә
кеше идарә итә торган
башкарма орган сыйфатында
түләүсез нигездә коммерцияле
булмаган оешмалар белән идарә
итүдә катнашырга яки аларның
коллегиаль идарә органнары
составына керергә рөхсәт бирү тәртибенә
1 нче кушымта

________________________________

________________________________
(Ф.И.О., замещаемая должность и
структурное

________________________________
подразделение, адрес места
жительства

________________________________
номер телефона)

Заявление
о разрешении представителем нанимателя государственному гражданскому служащему Республики Татарстан в Министерстве культуры Республики Татарстан_участвовать на безвозмездной основе в управлении некоммерческими организациями в качестве единоличного исполнительного органа или входить в состав их коллегиальных органов управления

Прошу разрешить мне участвовать в управлении, войти в состав коллегиального органа управления (нужное подчеркнуть)________________________________________________
(наименование общественной организации,
________________________________________________________________
жилищного, жилищно-строительного, гаражного кооператива, садоводческого, огороднического,
________________________________________________________________
дачного потребительского кооператива, товарищества собственников недвижимости)
на безвозмездной основе в качестве
________________________________________________________________.
(наименование единоличного исполнительного органа или коллегиального органа управления)

| | | |
|---|---|---|
| ____________ | ______________ | ________________________ |
| (дата) | (подпись) | (фамилия, инициалы) |

Татарстан Республикасы дәүләт
гражданлык хезмәткәренә яллаучы
вәкил тарафыннан Татарстан
Республикасы Мәдәният
министрлыгында бер генә
кеше идарә итә торган
башкарма орган сыйфатында
түләүсез нигездә коммерцияле
булмаган оешмалар белән идарә
итүдә катнашырга яки аларның
коллегиаль идарә органнары
составына керергә рөхсәт бирү тәртибенә
2 нче кушымта

## Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә яллаучы вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү турындагы гаризаларны теркәү ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Дата | Гариза бирүченең исем-фамилиясе, вазифасы | Гариза бирүченең имзасы | Җаваплы затның исем-фамилиясе | Җаваплы затның имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |